СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

14.04.2017 | с. Кильдеево | 24-114

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында”гы 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, “Муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару турында” Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советының 2016 елның 13 октябрендәге ПР-26-4 номерлы президиумы карарын игътибарга алып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставы нигезендә, җирле үзидарә органнары кабул иткән норматив хокукый базаны камилләштерү, унификацияләү һәм исәпкә алуны системага салу, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып баруга вәкаләтле вәкил итеп Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башкарма комитеты секретарен билгеләргә.

3.Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле затка әлеге карарның 1 пункты белән расланган акт нигезендә:

1) квартал саен хисап кварталыннан соң килгән 5 числога кадәр узган квартал өчен кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын формалаштырырга һәм хисап кварталыннан соң килүче 10 числога кадәр аларны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советының
2017 елның 14 апреленнән № 24-114 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмә (алга таба- Нигезләмә, реестрлар, җирле үзидарә органнары) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә норматив хокукый базаны камилләштерү, җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне унификацияләү һәм системалаштыру, муниципаль органнар эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында эшләнде.

1.2. Реестрлар түбәндәге бурычларны хәл итү өчен хезмәт итә:

норматив характердагы муниципаль хокукый актларны, алар турында белешмәләрне исәпкә алу, аларның законнарга туры килүен тикшереп тору;

коррупциягә каршы экспертиза уздыруның һәм муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгаруның үз вакытында башкарылуын тикшереп тору, актларның һәм алар турында белешмәләрнең законнарда билгеләнгән очракларда вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрелүен үз вакытында тикшереп тору;

вәкиллекле орган, муниципаль берәмлек башлыгы, башкарма комитеты һәм җирле үзидарәнең башка органнары, аларның вазыйфаи затлары һәм аппаратлары эшчәнлеген оператив мәгълүмат бирү һәм белешмә белән тәэмин итү;

муниципалитетның норматив хокукый базасында гражданнарның һәм юридик затларның, шул исәптән хуҗалык итүче субъектларның, иҗтимагый һәм башка кызыксынган оешмаларның, массакүләм мәгълүмат чараларының, контроль (күзәтчелек) органнарының һәм башкаларның файдалана алуын тәэмин итү.

1.3. Реестр - һәркем өчен мөмкин булган рәвештә рәсмиләштерелгән (махсус программа тәэминатыннан файдаланмыйча мәгълүматны чагылдырырга мөмкинлек бирә торган таблица форматында) һәм Нигезләмәнең 2 бүлегендә билгеләнгән тәртип нигезендә җирле үзидарә органының барлык муниципаль норматив хокукый актлары турында мәгълүматны үз эченә алган мәгълүматлар базасы .

1.4. Килди авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып барган һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырган өчен җаваплы зат булып Килди

авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре (муниципаль хокукый актлар нигезендә) тора.

## 2. Реестрлар төзү һәм алып бару

2.1. Реестрлар рус телендә электрон рәвештә алып барыла.

2.2. Реестрга муниципаль норматив хокукый актлар турында белешмәләр кертелә:

басылып чыкканнарын да, басылып чыкмаганнарын да;

гамәлдәге, шулай ук үз көчен югалткан яисә башка актлар белән үзгәртелгән;

башка актларга үзгәрешләр кертү яисә көчләрне югалту турында, башка актларның гамәлдә булу срокларын туктатып тору яисә озайту турында.

2.3. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советында алып барыла торган реестрларга (1 нче, 2, № 3 нче кушымталар) түбәндәге белешмәләр кертелә:

җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар турында;

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге советы кабул иткән карарлар, шулай ук Килди авыл җирлеге башлыгының норматив характердагы карарлары һәм күрсәтмәләре турында.

2.4. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Башкарма комитетында алып барылучы реестрга түбәндәге мәгълүматлар керә(4 нче кушымта):

норматив характердагы карарлар турында;

норматив характердагы күрсәтмәләр турында (норматив характерга ия аерым нигезләмәләр булган).

2.5. Реестрга түбәндәге белешмәләр кертелә:

хокукый акт төре;

кабул итү датасы;

теркәү номеры;

исеме.

2.6. Реестрга муниципаль норматив хокукый актлар турында түбәндәге өстәмә белешмәләр кертелергә тиеш:

бастырып чыгару (халыкка җиткерү) турында;

үзгәрешләр кертү (көчләрне югалту), суд тарафыннан гамәлдә түгел дип тану турында.

2.6.1. Реестрга муниципаль норматив хокукый актлар турында башка өстәмә мәгълүмат кертелергә мөмкин.

2.7. Муниципаль норматив хокукый актлар турындагы белешмәләр актлар кабул итү (басылу) датасы нигезендә реестрларда хронологик тәртиптә урнаштырыла.

2.8. Җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып барган өчен җаваплы зат квартал саен хисап кварталыннан соңгы кварталда кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын төзүне һәм аларны хисап кварталыннан соң Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында килүче 10 числога кадәр срокта урнаштыруны тәэмин итә.

## 3. Реестрлардагы мәгълүматны бирү тәртибе һәм шартлары. Мәгълүмати хезмәттәшлекнең башка мәсьәләләре

3.1. Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган реестрларда булган мәгълүмат һәркем файдалана алырлык булуы Аны кызыксынучы затлар тарафыннан электрон образлар (файллар) рәвешендә табу чикләнми.

3.2. Законнарда каралган очракларда реестрлардагы һәм вәкаләтле органнарга тапшырылырга тиешле белешмәләрне бирү тиешле норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Реестрлар алып бару тәртибен бозган өчен җаваплылык

4.1. Нигезләмәнең 1.4, 2.8 пунктларында күрсәтелгән җитәкчеләр һәм башка вәкаләтле затлар Нигезләмәдә билгеләнгән реестрларны алып бару тәртибен бозган өчен, шулай ук җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәгән өчен административ җаваплылыкка ия.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В.М.Бурдин

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә
1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советының муниципаль норматив хокукый актлары (карарлары) реестры

| №№ т/б | кабул итү көне | акт № | Акт исеме | Рәсми басылып чыгу (халыкка җиткерү) чыганагы һәм датасы | Искәрмәләр* |
|---|---|---|---|---|---|
| 2017 елның апрель-июнь | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегендә җирле референдумнарда кабул ителгән карарларның муниципаль норматив хокукый актлары рәвешендә рәсмиләштерелгән реестры

| № № т/б | кабул итү көне | акт № | Акт исеме | Рәсми басылып чыгу (халыкка җиткерү) чыганагы һәм датасы | Искәрмәләр* |
|---|---|---|---|---|---|
| 2017 елның апрель-июнь | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының муниципаль норматив хокукый актлары реестры

| №№ т/б | кабул итү көне | акт № | Акт исеме | Рәсми басылып чыгу (халыкка җиткерү) чыганагы һәм датасы | Искәрмәләр* |
|---|---|---|---|---|---|
| 2017 елның апрель-июнь<br>Карарлар | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Боерыклар | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә

4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты муниципаль норматив хокукый актлар РЕЕСТРЫ

| №№ т/б | кабул итү көне | акт № | Акт исеме | Рәсми басылып чыгу (халыкка җиткерү) чыганагы һәм датасы | Искәрмәләр* |
|---|---|---|---|---|---|
| 2017 елның апрель-июнь<br>Карарлар | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Боерыклар | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |